МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.02.2018 Казан ш. № 02-17

Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар биргәндә максатчан билгеләнешле субсидия, субвенция, башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 219 статьясындагы $2^1$ пункты нигезендә, боерык бирәм:

1.Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар биргәндә максатчан билгеләнешле субсидия, субвенция, башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет бүлегенә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының финанслау бүлекләренә Россия Федерациясе Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең финанс органнарына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды идарәсе органына бу боерыкның үз көченә керүе датасына, бу боерык үз көченә кергәннән соң биш эш көне эчендә, бүленүе 2018 елга һәм планда каралган 2019 һәм 2020 елгы чорларга Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджеты росписендә исәпкә алынган, максатчан билгеләнешкә ия булган субсидия, субвенция, башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры урынбасары Р.А. Аюкасовка бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән уведомлениеләрне формалаштыруны «АЦК-Финансы» программасында техник яктан хәл кылуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерык рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2018 елга һәм планда каралган 2019 һәм 2020 елларга Татарстан Республикасы бюджетын үтәүдән башлап кулланыла.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс
министрлыгының
20 февраль, 2018 ел
№ 02-17 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар биргәндә максатчан билгеләнешле субсидия, субвенция, башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 219 статьясындагы $2^1$ пункты нигезендә эшләнде, һәм ул “Федераль бюджеттан субсидия, субвенция, башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление формасын һәм максатчан билгеләнешле бюджетара транфертлар биргәндә аларны бирү тәртибен раслау турында” 29 ноябрь, 2017 ел, № 213н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган формада Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар (алга таба – бюджетара трансфертлар) биргәндә максатчан билгеләнешле субсидия, субвенция, башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү кагыйдәләрен билгели.

2. Уведомление Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең финанс органнарына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды идарәсе органына җибәрелә.

3. Уведомление Министрлык тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы законы белән (агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында законга үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы белән) бюджетара трансфертлар бүлү расланганнан соң эш көннәрендә исәпләнелә торган 15 көн эчендә җибәрелә.

4. Бюджетара трансферт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты (алга таба – Акт) нигезендә бүленгән очракта (бүлүгә үзгәрешләр кертү) үзенә әлеге бюджетара трансфертларны бирүгә бюджет ассигнованиеләре күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүче (алга таба – баш

бүлүче) Бюджетара транфертны бүлү (бүлүгә үзгәрешләр кертү) турында акт күчермәсен тапшыра:

Акт Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписенә үзгәрешләр кертүне таләп иткән очракта – бер үк вакытта билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджеты росписенә үзгәрешләр кертү тәкъдиме белән, Министрлыкка;

Акт Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписенә үзгәрешләр кертүне таләп итмәгән очракта – Акт үз көченә кергәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына.

Уведомление баш бүлүче тарафыннан Бюджетара трансфертны бүлү (бүлүгә үзгәрешләр кертү) турында акт күчермәсе тапшырылганнан соң эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көн эчендә җибәрелә.

5. Уведомление «АЦК-Финансы» программасында Министрлык исеменнән эш итүгә вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имазаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә:

Министрлыкның бюджет бүлеге тарафыннан – баш бүлүчесе Министрлык булып торган бюджетара трансфертлар буенча;

үзенә тиешле өлкәдә чыгымнарны түләүгә санкцияләрне хәл кылу билгеләнгән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының финанслау бүлеге тарафыннан – баш бүлүчеләре Татарстан Республикасының тиешле министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары булып торган бюджетара трансфертлар буенча.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең финанс органнары, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүнең территориаль фонды идарәсе органы Министрлык Уведомлениене җибәргәннән соң эш көннәрендә исәпләнелә торган өч көн эчендә «АЦК-Финансы» программасында Уведомлениене алуны һәм алу фактын раслауны тәэмин итә. Раслау электрон документ рәвешендә формалаштырыла һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең финанс органы, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүнең территориаль фонды идарәсе органы тарафыннан эш итүгә вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдалану нигезендә электрон рәвештә Уведомление җибәрү һәм Уведомление алу фактын раслауның техник мөмкинлеге булмаганда:

Министрлык тарафыннан Уведомлениене формалаштыру һәм җибәрү электрон рәвештә Уведомлениеләр формалаштыру өчен бу Тәртиптә күздә тотылган срокта, билгеләнгән тәртиптә имзаланган, кәгазь документ рәвешендә хәл ителә;

Уведомление алу фактын раслау кәгазьдә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең финанс органы, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүнең территориаль фонды идарәсе органы исеменнән эш итүгә вәкаләтле затның имзасы белән Министрлыктан Уведомление алынганнан соң эш көннәрендә исәпләнелә торган өч көн эчендә хәл ителә.